Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ
05 апрель 2023 ел

КАРАР
№ 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр керту хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр керту турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы Прокуратурасы 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүмат нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Әлмәт авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 сентябрендәге 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктына «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.